КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 25 ноябрь г.Казань № 1126

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 31 август, 793 нче карары белән расланган 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыру кысаларында 2021 елда федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджетара трансфертлар бирү буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына мәҗбүри медицина иминләштерүе буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) һәм (яисә) авыруга карата шик белән затларга медицина ярдәме күрсәтүне өстәмә финанс белән тәэмин итүгә бирелә торган максатчан билгеләнеше булган башка бюджетара трансферттан файдалану тәртибенә үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда территориаль мәҗбүри медицина иминияте программаларын тормышка ашыру кысаларында мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы һәм (яки) аның белән авыруга шик булган затларга медицина ярдәме күрсәтүне өстәмә финанслар белән белән тәэмин итү өчен тиешле

территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар бирү буенча Россия Федерациясе субъектларының һәм Байконур шәһәренең чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына һәм Байконур шәһәре бюджетына федераль бюджеттан максатчан билгеләнешкә ия башка бюджетара трансферлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 ел, 29 октябрь, 1855 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыру кысаларында 2021 елда федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджетара трансфертлар бирү буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына мәҗбүри медицина иминләштерүе буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) һәм (яисә) авыруга карата шик белән затларга медицина ярдәме күрсәтүне өстәмә финанс белән тәэмин итүгә бирелә торган максатчан билгеләнеше булган башка бюджетара трансферттан файдалану тәртибен раслау турында» 2021 ел, 31 август, 793 нче карары белән расланган 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыру кысаларында 2021 елда федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджетара трансфертлар бирү буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына мәҗбүри медицина иминләштерүе буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) һәм (яисә) авыруга карата шик белән затларга медицина ярдәме күрсәтүне өстәмә финанс белән тәэмин итүгә бирелә торган максатчан билгеләнеше булган башка бюджетара трансферттан файдалану тәртибенә, 3 пункттагы «30 июненә» сүзләрен «31 августына» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин